| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13 апрель 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 24 декабрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә яшәргә килгән гражданнарның беренчел хәрби исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 24 декабрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә яшәргә килгән гражданнарның беренчел хәрби исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

2.7.2. Гражданин гаилә хәле, белеме, эш урыны, вазыйфасы һәм яшәү урыны турында үзгәрешләр кертү турында мөрәҗәгать иткән очракта түбәндәге документлар тапшырырга кирәк:

- гаилә хәле үзгәргән очракта - паспорт (тиешле тамгалары белән) яисә чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

- граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;

белем алу һәм (яки) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында документлар һәм чит ил дәүләте территориясендә бирелгән уку узу белән бәйле документлар, һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

-белем алу һәм (яки) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында документлар һәм чит ил дәүләте территориясендә бирелгән уку узу белән бәйле документлар, һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

- белем һәм (яки) квалификация турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында, хәрби һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем хәрби мәгариф оешмалары тарафыннан бирелә торган, шулай ук 1992-1995 елларда Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан бирелгән документлар;

- эш урыны, вазыйфасы, хезмәт кенәгәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

- яшәү урыны үзгәргән очракта-паспорт (яңа яшәү урыны, теркәлү турындагы тиешле билге белән).

б) 3.7.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-25 декабрьгә кадәр-агымдагы елда беренчел хәрби исәпкә алу нәтиҗәләре турында хисап.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, Гагарин ур., 5, Подлесный бистәсе, Гагарин ур., 1б, Иске Писмән авылы, Үзәк ур., 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов